Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумбут авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 10**

Шумбут авылы 2018 елның 21 сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Шумбут авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты “в” пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шумбут авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 27 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 9 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. . Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

“Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, һәрбер кешенең 2018 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

- кышын авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны карап торуга һәм ремонтлауга;

-авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын карап торуга;

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүгә

юнәлтүгә Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумбут авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шумбут авылы, Совет урамы, 18 нче йорт; Шумбут авылы, Завод урамы, 22 нче йорт; Шестая Речка авылы, Урман урамы,.6 нчы йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумбут авыл җирлеге башлыгы Н.Е.Сергеев